# Туган телем – татар теле

# Мин табигатьне яратам

(8 нче дәрес)

# Ел фасыллары

Дүрт ел фасылы бар: яз, җәй, көз, кыш.

Һәр ел фасылы матур.



# Елның дүрт фасылы

**(Габдулла Тукай)**

Боз һәм кар эрде,
Сулар йөгерде;
Егълап елгалар,
Яшьләр түгелде.

Көннәр озая,
Төннәр кыскара.
Бу кайсы вакыт? —
Йә, әйтеп кара.



*(Яз көне)*

# Елның дүрт фасылы

**(Габдулла Тукай)**

Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште;
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.



Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура,—
Бу кайчак була?

*(Җәй көне)*



# Елнын дүрт фасылы

**(Габдулла Тукай)**



Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява;
Җирләр дымлана,—
Бу кайчак була?

*(Көз көне)*

# Елның дүрт фасылы

**(Габдулла Тукай)**

Һәр җир карланган,
Сулар бозланган;
Уйный җил-буран,—
Бу кайчак, туган?



*(Кыш көне)*



# Бу кайсы вакыт?



Яз, яз, яз җитә,
Тәрәзәне ачтылар.
Тып-тып, тып-тып, тып итә
Эре-эре тамчылар.

*(Фатих Кәрим)*

Күрәсезме, бакчада
Пешә чия, алмалар.
Кояшлы саф һавада
Уйныйлар кыз балалар.



*(Мөнир Мазунов)*

# Табышмаклар



- Лампа түгел – якты,
  Мич түгел – җылы. *(Кояш)*

- Ак ашъяулык таптык,
  Җир өстенә яптык. *(Кыш)*

- Бабай килгән сагынып,
  Ак чикмәнен ябынып. *(Кыш)*





**Дәрес тәмам, дуслар!**

**Сау булыгыз!**